**Азнакай муниципаль районы**
**Бирючевка авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Бирючевка авылы № 29 «20» октябрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Бирючевка авыл җирлегенең 2014 елның 13 маендагы 88 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Бирючевка авыл җирлеге чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чаралары турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлегенең торак пуктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (04.03.2016 №28, 02.09.2022 №43 карарлар редакциясендә)

«Янгыннан иректе саклау турында»гы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 4 августыннан 445-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Бирючевка авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Бирючевка авыл җирлегенең 2014 елның 13 маендагы 88 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Бирючевка авыл җирлеге чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чаралары турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлегенең торак пуктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (04.03.2016 №28, 02.09.2022 №43 карарлар редакциясендә) 1.4 пунктының 7, 8 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

“Ирекле янгын сакчылары - янгыннан ирекле саклау буенча иҗтимагый берләшмәләрне, ирекле янгын сүндерүчеләр бүлекчәләрен һәм алар составына керүче ирекле янгын сүндерү бүлекчәләрен үз эченә алган, эшчәнлекләре янгыннарны профилактикалауда һәм (яисә) сүндерүдә һәм һәлакәттән коткару эшләрен уздыруда катнашу каралган ирекле янгын саклау төре;

- ирекле янгын сүндерүче - янгыннарны профилактикалауда һәм (яисә) янгын сүндерүдә һәм ирекле янгын сүндерү бүлекчәсе составында авария-

коткару эшләрен уздыруда ирекле һәм түләүсез нигездә катнашучы физик зат.».

2. Әлеге карар 2024 елның 01 февраленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис З.Г.Солтанова